РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«15» май 2023 ел Олы Кайбыч ав. № 193

Кайбыч муниципаль районы Советының 2021 елның 20 декабрендәге 92 номерлы карары белән расланган Кайбыч муниципаль районы җирлекләре территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив-хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Кайбыч муниципаль районы җирлекләре территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында» 2021 елның 20 декабрендәге 92 номерлы Кайбыч муниципаль районы Советы карары белән расланган Кайбыч муниципаль районы җирлекләре территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында нигезләмәгә түбәндәге эчтәлекле сигезенче бүлек белән өстәп, үзгәрешләр кертергә:

«8. Кайбыч муниципаль районы җирлекләре территорияләрендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата башкарма комитет карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять белдерү

8.1. Кайбыч муниципаль районы җирлекләре территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затларның карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 9 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.

8.2. Алар фикере буенча, Кайбыч муниципаль районы җирлекләре территорияләрен төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында хокук һәм законлы мәнфәгатьләре турыдан-туры бозылган дип

санаучы контрольдә торучы затлар түбәндәгеләргә судка кадәр шикаять бирергә хокуклы:

1) контроль чаралар уздыру турында карарларга;

2) ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында контроль чаралар актларына, күрсәтмәләргә;

3) контроль чаралар кысаларында Кайбыч муниципаль районы җирлекләре территорияләрендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмауларына).

8.3. Шикаять контрольдә торучы зат тарафыннан шикаятьне карауга вәкаләтле орган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталын һәм (яисә) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең региональ порталын кулланып электрон рәвештә тапшырыла.

Дәүләт яисә закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләр һәм документларны үз эченә алган шикаять, дәүләт сере турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен исәпкә алып, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең региональ порталыннан файдаланмыйча бирелә.

Тиешле шикаять Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы башлыгының шәхси кабул итүендә контрольдә торучфы зат тарафыннан шикаятьтә (документларда) закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләрнең булуы турында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы башлыгына алдан хәбәр итеп бирелә.

8.4. Башкарма комитет карарына шикаять, аның вазыйфаи затларының гамәлләре (гамәл кылмавы) Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы башлыгы (башлыгы урынбасары) тарафыннан карала.

8.5. Башкарма комитет карарына шикаять, аның вазыйфаи затларының гамәлләре (гамәл кылмавы) контрольдә тотыла торган зат үз хокукларын бозу турында белгән яки белергә тиеш булган көннән алып 30 календарь көн эчендә бирелергә мөмкин.

Башкарма комитет күрсәтмәсенә шикаять контрольдә тотылган зат тарафыннан күрсәтмә алынган вакыттан алып 10 эш көне эчендә бирелергә мөмкин.

Шикаять бирү срогын җитди сәбәп аркасында уздырган очракта, шикаятьне биргән затның үтенече буенча бу срок башкарма комитет (шикаятьне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат) тарафыннан торгызылырга мөмкин.

Шикаять биргән зат шикаять буенча карар кабул ителгәнчегә кадәр аны тулысынча яки өлешчә кире алырга мөмкин. Шул ук вакытта шул ук нигезләр буенча кабат шикаять бирү рөхсәт ителми.

8.6. Башкарма комитет карарына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять аны теркәгәннән соң 20 эш көне эчендә каралырга тиеш.

Аны карау өчен башка органнар карамагында булган белешмәләр алу таләп ителгән очракта, шикаятьне карау срогы Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы башлыгы (башлыгы урынбасары) тарафыннан 20 эш көненә озайтылырга мөмкин.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

Кайбыч муниципаль районы Башлыгы,
Совет Рәисе А.И.Рәхмәтуллин